ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Мәдәният турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«яшь белгеч – мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган елда дәүләт яисә муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасына белем алу һәм (яисә) квалификация турындагы документында күрсәтелгән квалификациясенә ярашлы рәвештә эшкә кергән, 30 яше тулмаган зат (алга таба – яшь белгеч).»;

2) $10^2$ статьяда «(тарих һәм мәдәният ядкарьләрен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 14 статьяда «предприятиеләр, учреждениеләр,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 16 статьяда:

а) икенче абзацта «республика максатчан программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28 статья. **Мәдәният хезмәткәрләренә социаль ярдәм**

Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләренә карата Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының мәгариф турындагы законнары гамәлдә була.

Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында урнашкан Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына яисә муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына эшкә кергән яшь белгечләргә бер мәртәбә бирелә торган пособие түләнә. Әлеге бер мәртәбә бирелә торган пособие Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән түләнә, аның күләме һәм аны түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары белгечләренә башка социаль ярдәм чаралары җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

Керемнәренең бердәнбер чыганагы авторлык түләве булган иҗади берлекләр һәм ассоциацияләр әгъзалары, шулай ук иҗади берлекләр әгъзалары булып тормаган башка иҗади хезмәткәрләр, Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият кертемнәрен түләгән очракта, иминият пенсиясенә хокуклы.»;

6) $28^1$ статьяда:

а) икенче өлештә «(учреждениеләре)» сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче өлештә «(учреждениеләре)» сүзен төшереп калдырырга;

7) $28^2$ статьяның икенче өлешендә «(учреждениеләренә)» сүзен төшереп калдырырга;

8) 30 статьяда «, учреждениеләренең» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 26 октябрь
№ 77-ТРЗ